**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы карары**

Үчәлле авылы № 178 19 май 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте**:**

1. Кушымта итеп бирелгән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын ( 05.10.2013 №75, 17.03.2014 №91, 15.08.2014 №112, 25.08.2017 №63, 13.11.2018 №118) карарлар редакциясендә) хупларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрендагы 52 номерлы карары ( 05.10.2013 №75, 17.03.2014 №91, 15.08.2014 №112, 25.08.2017 №63, 13.11.2018 №118 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты – 2020 елның 28 маеннан 2020 елның 30 июненә кадәр;

- үткәрү урыны – Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 30 июненә кадәр- Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

-Төхвәтуллина Г.М.– Үчәлле авыл җирлеге башлыгы;

-Владимиров О.И. –Үчәлле авыл җирлеге Советының №6 округ депутаты;

-Зиятдинова Н.Р. –Үчәлле авыл җирлеге Советының №3 округ депутаты;

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрендагы 52 номерлы карары (05.10.2013 №75, 17.03.2014 №91, 15.08.2014 №112, 25.08.2017 №63, 13.11.2018 №118 карарлар редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2020 елның 25 маеннан да соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл Советының
2020 елның 19 маендагы 178
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы карары**

Үчәлле авылы №___ __ ______ 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябрендагы 52 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (05.10.2013 №75, 17.03.2014 №91, 15.08.2014 №112, 25.08.2017 №63,13.11.2018 №118 карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябрендагы 52 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (05.10.2013 №75, 17.03.2014 №91, 15.08.2014 №112, 25.08.2017 №63, 13.11.2018 №118 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.11.13 пунктта:
а) «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар»

сүзләренә алмаштырырга;

б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.2. 2.11.16 пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.18 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.18. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина